СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_12_» ноябрь 2021 ел** **№ 99**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексының 84 һәм 98 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль контроле территориясендә муниципаль урман контроле турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
___________ ел, №__
карарына кушымта

Арча муниципаль районы территориясендә
муниципаль урман контроле турында
Нигезләмә

1. Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә, муниципаль урман контроле) Арча муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Муниципаль урман контроле предметы булып юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба - контрольдә тотылучы затлар) тарафыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милкендәге урман кишәрлекләренә карата, урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү һәм урман үрчетү өлкәсендә, шул исәптән урман үсемлекләре орлыкларына карата орлыкчылык өлкәсендә билгеләнгән урман законнары таләпләрен үтәү тора.

3. Муниципаль урман контроле объектлары (алга таба - контроль объектлары):

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милкендәге урман кишәрлекләре территориясендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан җитештерү һәм урман үрчетү буенча урман хуҗалыгы өлкәсендә контрольдә тотылучы затлар эшчәнлеге;

2) аларда урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү һәм урман үрчетү буенча эшчәнлек алып барыла торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милкендәге урман кишәрлекләре;

3) урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу һәм урман үрчетү белән бәйле объектлар, шул исәптән стационар объектлар, җиһазлар, җайланмалар, предметлар, материаллар, транспорт чаралары.

4. Муниципаль урман контроле түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Урман кодексы;

2) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

4) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон.

5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милкендәге урман кишәрлекләренә карата муниципаль урман контролен Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

6. Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чаралар уздыру турында карар кабул итәргә вәкаләтле вазифаи затлар:

а) вәкаләтле орган җитәкчесе.

7. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органның вазифаи затлары (алга таба - вазифаи затлар):

а) вәкаләтле орган җитәкчесе;

б) вәкаләтле органның вазифаи инструкцияләре нигезендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру йөкләнгән муниципаль хезмәткәрләре.

8. Вәкаләтле орган муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган контроль чаралар (алга таба - контроль чаралар) үткәрә.

9. Вәкаләтле орган муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын исәпкә алуны контроль объектлары турында белешмәләр кертү юлы белән "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы таләпләре нигезендә мондый белешмәләр кергән көннән ике көннән дә соңга калмыйча тәэмин итә.

Контроль объектлары турында белешмәләр җыйганда, эшкәрткәндә, анализлаганда һәм исәпкә алганда, вәкаләтле орган норматив хокукый актлар нигезендә тапшырыла торган мәгълүматтан, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган, шулай ук һәркем файдалана алырлык мәгълүматтан файдалана.

10. Муниципаль урман контроле закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычын бәяләү һәм идарә итү системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычы белән идарә итү максатларында контроль объектлары түбәндәге куркынычлылык категорияләренең берсенә кертелергә тиеш:

а) югары куркынычлылык;

б) уртача куркынычлылык;

в) түбән куркынычлылык.

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектының вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән куркынычлылык категориясенә кертелү әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә башкарыла.

12. Контроль объектларын куркынычлылык категориясенә кертү һәм билгеләнгән куркынычлылык категорияләрен үзгәртү вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган җитәкчесе объектның куркынычлылыкның башка категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркынычлылык критерийлары үзгәрү турында белешмәләр кергән көннән соң биш эш көне эчендә контроль объектының куркынычлылык категориясен үзгәртү турында карар кабул итә.

Контроль объектларын куркынычлылык категориясенә кертү турында карар булмаса, мондый контроль объектлары куркынычлылыкның түбән категориясенә кертелгән дип санала.

Контроль объектларын түбән куркынычлылык категориясенә кертү турында карар кабул итү таләп ителми.

13. Куркынычлылык категориясенә бәйсез рәвештә, контрольдә тотылучы затларга карата вәкаләтле орган тарафыннан тикшереп торылган контроль чаралар үткәрү түбәндәге вакытта гамәлгә ашырыла:

1) югры куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен - 2 елга бер тапкыр;

2) уртача куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен - 3 елга бер тапкыр.

Түбән куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль чаралар уздырылмый.

14. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелә.

15. Вәкаләтле орган куркынычлылык категориясе бирелгән контрольдә тотылучы затлар исемлеген алып бара.

16. Контрольдә тотылучы затның гарызнамәсе буенча вәкаләтле орган сорату кергәннән соң 15 көннән дә артмаган срокта контрольдә тотылучы затка куркынычлылык категориясе турында мәгълүмат, шулай ук контрольдә тотылучы затны куркынычлылык категориясенә керткәндә кулланылган белешмәләрне бирә.

Контрольдә тотылучы зат вәкаләтле органга элек бирелгән куркынычлылык категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.

17. Вәкаләтле орган муниципаль урман контролен үткәрүне түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыра:

1) профилактик чаралар;

2) контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә һәм контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлексез үткәрелә торган контроль чаралар.

18. Профилактик чаралар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль милкендәге урман кишәрлекләренә зыян (зарар) килү куркынычын профилактикалау программасы (алга таба - профилактика программасы) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Профилактикалауның расланган программасы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - "Интернет" челтәре) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы хакимиятенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Профилактик чаралар уздырганда контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычы туу яки мондый зыян (зарар) килү ачыкланган очракта, вазифаи затлар, контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, бу хакта кичекмәстән вәкаләтле орган җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына) хәбәр итәләр.

19. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда түбәндәге профилактик чаралар төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) мәгълүмат җиткерү;

2) кисәтү игълан итү;

3) консультация бирү.

20. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерү вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль урман контролен гамәлгә ашыруга кагылышлы белешмәләрне "Интернет" челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы администрациясенең рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә каралган белешмәләрне «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы хакимиятенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм аны актуаль хәлдә тотарга тиеш.

21. Мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү чараларын күрү тәкъдиме белән мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турындагы кисәтү (алга таба - кисәтү) вазифаи затның мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булу турында белешмәләр булганда һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне

бозуның закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе яки зыян (зарар) китерү куркынычы туу игълан ителә.

Кисәтүләрне исәпкә алу вәкаләтле орган тарафыннан кисәтүләрне теркәү номеры биреп, исәпкә алу журналын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла.

Контрольдә тотылучы зат кисәтү алган көннән алып 15 календарь көн эчендә күрсәтелгән кисәтүгә карата вәкаләтле органга түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган ризасызлык (алга таба - ризасызлык) белдерергә хокуклы:

1) юридик затның исеме, шәхси эшкуарның яисә гражданның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), шулай ук контакт телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм контрольдә тотылучы затка җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

2) мондый кисәтүне җибәргән вазифаи зат һәм кисәтү турында белешмәләр;

3) контрольдә тотылучы зат игълан ителгән кисәтүләр белән риза булмауны раслый торган дәлилләр;

4) шәхси имза һәм дата.

Ризасызлык контрольдә тотылучы зат тарафыннан кәгазьдә язмача почта аша яки электрон имза белән изаланып, "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Вәкаләтле орган ризасызлыкны теркәгән көннән алып 30 календарь көн эчендә:

1) ризасызлыкны объектив, һәрьяклап һәм үз вакытында карауны тәэмин итә, кирәк булганда, ризасызлык биргән контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкаләтле вәкиле катнашында;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан һәм башка затлардан документлар һәм материаллар соратып ала;

3)ризасызлыкны карау нәтиҗәләре буенча контрольдә тотылучы затның бозылган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрә;

4) ризасызлыкның асылы буенча язмача җавап җибәрә.

Ризасызлыкны карау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) игълан ителгән кисәтүне гамәлдән чыгару рәвешендә ризасызлыкны канәгатьләндерә;

2) ризасызлыкны канәгатьләндерүдән баш тарта.

22. Контрольдә тотылучы затларга консультация бирү вәкаләтле органның вазифаи заты тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхсән кабул иткәндә яки профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрү барышында гамәлгә ашырыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнарны шәхсән кабул итү вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы администрациясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Консультация бирү түбәндәге мәсьәләләр буенча телдән һәм язма рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль урман контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

3) вәкаләтле органның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү тәртибе;

4) аларның үтәлешен бәяләү контроль чаралар кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләре булган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат бирү.

Вазифаи зат тарафыннан язма рәвештә консультация бирү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) контрольдә тотылучы зат тарафыннан консультация бирү мәсьәләләре буенча язма җавап бирү турында язма гарызнамә бирелгәндә;

2) куелган сорауларга җавап бирү мөмкин булмаганда;

3) куелган сорауларга җавап өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп иткәндә.

Консультация биргәндә вазифаи зат Россия Федерациясе законнары нигезендә керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш.

Вәкаләтле орган консультацияләрне исәпкә алу журналын алып бара.

Календарь ел дәвамында вәкаләтле органга контрольдә тотылучы затлардан һәм аларның вәкилләреннән 5 һәм аннан күбрәк бер типтагы мөрәҗәгать кергән очракта, консультация язма аңлатмалар рәвешендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бирелә.

23. Вәкаләтле орган муниципаль урман контролен үткәрүне түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыра:

1) контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек иткәндә үткәрелә торган контроль чаралар;

2) контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлексез уздырыла торган контроль чаралар.

24. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда күрсәтелгән чаралар кысаларында контроль чараларның һәм контроль гамәлләрнең түбәндәге төрләре үткәрелергә мөмкин:

инспекция визиты (тикшерү, сораштыру, инструменталь тикшерү, язма аңлатмалар алу);

рейд тикшерүе (тикшерү, сораштыру, инструменталь тикшерү, язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу);

документлар буенча тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу);

урынга барып тикшерү (тикшерү, сораштыру, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу);

мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә торган белешмәләрне, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль системаларда булган белешмәләрне, "Интернет" челтәрендәге мәгълүматларны, башка иҗтимагый белешмәләрне җыю, анализлау);

күчмә тикшерү (тикшерү, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып) үткәрү.

25. Күчмә тикшерү һәм мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү вәкаләтле орган тарафыннан контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлексез уздырыла.

26. Әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында күрсәтелгән контроль чаралар, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүдән һәм күчмә тикшерүдән тыш, планлы һәм планнан тыш контроль чаралар рәвешендә уздырыла.

27. Күчмә тикшерүне үткәрү срогы 10 эш көне тәшкил итә.

28. Пробалар (үрнәкләр) алу контроль чараны үткәрүгә җәлеп ителгән эксперт (белгеч) тарафыннан контроль чараны уздыру барышында турыдан-туры гамәлгә ашырыла. Пробалар (үрнәкләр) алу түбәндәге гамәлләрнең эзлеклелеген үз эченә ала:

а) алынырга тиешле пробаларны (үрнәкләрне) һәм алу нокталарын билгеләү (сайлау);

б) таләп ителә торган пробаны (үрнәкне) алу ысулын билгеләү, таләп ителә торган пробаны (үрнәкне) алу максатында матдә, материал яисә продукция пробаларын (үрнәкләрен) әзерләү яисә эшкәртү;

в) пробаны (үрнәкне) алу һәм аны төрү.

Пробаларны (үрнәкләрне) алганнан соң вазифаи зат тарафыннан пробаларны (үрнәкләрне) алу беркетмәсе төзелә, беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә: беркетмәне төзү номеры һәм датасы; әгәр алар икедән артык сайлап алынган булса, һәр пробаның (үрнәкнең) тәртип номеры; пробаны алу датасы һәм урыны; пробаны җибәрү максаты; пробаларны алуны үткәргән юридик затның (тәэмин итүче, кабул итүче яки контроль органы) атамасы һәм адресы; пробаны (үрнәкләрне) алуны үткәргән затның фамилиясе һәм вазифасы күрсәтелә.

Алынган пробалар (үрнәкләр) пробалар (үрнәкләр) алу беркетмәсенә кушымта итеп бирелә.

Пробалар (үрнәкләр) алу беркетмәсе контроль чара актына кушымта итеп бирелә, беркетмәнең күчермәсе контрольдә тотылучы затка яисә аның вәкиленә тапшырыла.

Контроль чаралар уздырганда контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле булмаганда, пробалар (үрнәкләр) алу мәҗбүри рәвештә видеоязма кулланып уздырыла. Пробалар (үрнәкләр) алу кул инструментын кулланып, пробалар (үрнәкләр) алуга дучар ителгән предметларның сыйфат характеристикаларын бозмыйча яисә начарайтмыйча башкарыла.

Үрнәкләр алу мөмкин булмаган продукция (товарлар) төрләре юк.

29. Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле булмаганда, контроль чаралар башкарганда тикшерү үткәрү (досмотр) рөхсәт ителми.

30.Вәкаләтле органга шәхси эшкуар, контрольдә тотылучы зат булган граждан форс-мажор шартлары (шәхси эшкуарның, гражданның вакытлыча эшкә яраксызлыгы, башка торак пунктта эш сәфәрендә булу) аркасында контроль чара үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат тапшырган очракта, вәкаләтле орган контроль чара үткәрүне шәхси эшкуарның, гражданның мондый мөрәҗәгате өчен сәбәп булган әлеге хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерә.

31. Вәкаләтле орган контроль чараны контрольдә тотылучы затларга карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1 - 5 пунктларында һәм 2 өлешендә каралган нигезләрдә гамәлгә ашыра.

32. Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлектә уздырыла торган контроль чаралар вәкаләтле органның контроль чараны уздыру турындагы карары нигезендә уздырыла.

33. Контроль чара аны төзү һәм алып бару кагыйдәләрендә билгеләнгән контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелгәннән соң башлана ала, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен һәм күчмә тикшерүнең үтәлүен күзәтүдән,

шулай ук реестр операторы тарафыннан теркәлгән контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрының эшкә яраксызлыгы очракларыннан тыш.

34. Планлы контроль чаралар вәкаләтле орган төзи торган һәм прокуратура органнары белән килештерелергә тиешле чираттагы календарь елга планлы контроль чараларны үткәрү планы нигезендә (алга таба - еллык план) уздырыла.

Вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан расланган еллык план Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 31 декабрендәге "Чираттагы календарь елга планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән килештерү, аңа кертү һәм аннан ел дәвамында контроль (күзәтчелек) чараларын төшереп калдыру тәртибе турында" 2428 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә төзелә.

35. Контроль объектларын куркынычлылык категориясенә керткәндә, куркынычлылык критерийларын кулланганда һәм урман законнарының мәҗбүри таләпләрен бозуның куркынычлылык индикаторларын ачыклаганда, вәкаләтле орган тарафыннан зыян (зарар) китерү куркынычы дәрәҗәсен характерлый торган Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, аларның дөреслеген тәэмин итә торган теләсә кайсы чыганаклардан, шул исәптән профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрү, дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) махсус режимнарын куллану барышында, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалардан, контрольдә тотылучы затларның, башка гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләреннән, массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләреннән, шулай ук мәгълүмат ресурсларындагы белешмәләр, шул исәптән мәгълүматны маркировкалау, күзәтү, исәпкә алу, автомат рәвештә теркәүне тәэмин итә торган белешмәләр һәм контроль объектлары турында, шул исәптән ачык мәгълүмат чыганакларыннан алынган белешмәләр кулланыла.

36. Аларны куркынычлылык категориясенә кертү яки урман законнарының мәҗбүри таләпләрен бозу куркынычы индикаторларын билгеләү максатларында контроль объектлары турында белешмәләр җыю, эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алу контрольдә тотылучы затлар белән хезмәттәшлек итмичә башкарыла.

37. Вәкаләтле орган закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү яисә зыян (зарар) килү куркынычы туу турында белешмәләрне тикшергәндә, шул исәптән гражданнар мөрәҗәгатьләрендә булган, вәкаләтле орган тарафыннан алынган белешмәләрнең дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар уздыра, шуннан соң контроль объектының куркынычлылык категориясе яңадан карала яисә раслана.

38. Контроль яисә профилактик чара үткәргәндә вазифаи затлар үз компетенциясе чикләрендә аудио- һәм видеоязма, фотоаппаратлардан файдаланырга, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сергә кертелгән

объектлар һәм документлардан тыш, аудиоязма, фотога һәм видеога төшерергә хокуклы. Контроль чара үткәргәндә аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү кирәклеге турындагы карар вазифаи зат тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә. Күчмә тикшерү барышында мәҗбүри тәртиптә мәҗбүри таләпләрне бозуны фото- һәм видеога төшерү ярдәмендә дәлилләү гамәлгә ашырыла.

Аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү контрольдә тотылучы затка мәҗбүри хәбәр итеп башкарыла.

Аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү контроль чараны уздыру барышында, язманы гамәлгә ашыруның датасы, урыны, вакыты һәм тәмамлануы турында хәбәр итеп, өзлексез рәвештә башкарыла. Яздыру барышында мәҗбүри таләпләрне бозуның урыны һәм характеры җентекләп теркәлә.

Аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта чагыла.

Аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү нәтиҗәләре контроль чара актына кушымта булып тора.

Мәҗбүри таләпләрне бозуны дәлилләүне теркәү өчен аудиоязма, фото- һәм видеога төшерү дәүләт серен яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

39. Контроль чара нәтиҗәләренә контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү һәм (яисә) аларны бозуларны туктату өчен шартлар тудыру, бозылган хәлне торгызу, җаваплылыкка тарту һәм (яисә) контроль органы тарафыннан "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны куллану турындагы мәсьәләне карау өчен вәкаләтле орган яисә вазифаи зат тарафыннан мәгълүмат җибәрү керә.

40. Контроль чаралар уздырганда контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, вәкаләтле орган Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң, контрольдә тотылучы затка ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында, аларны бетерү вакытының һәм (яки) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

2) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килүне булдырмау яисә аны туктату буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә һәм гражданнар, оешмалар игътибарына закон

тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычы булу турында һәм аны булдырмау ысуллары турында мәгълүмат җиткерү буенча, әгәр контроль чараны үткәргәндә гражданның, контроль объектка ия булган һәм (яисә) файдаланыла торган оешмаларның эшчәнлеге закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудырганда яисә мондый зыян (зарар) китерелгән очракта, аны булдырмау ысуллары булу турында мәгълүмат җиткерергә;

3) контроль чара барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, бу хакта мәгълүматны тиешле дәүләт органына җибәрергә;

4)мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килүне булдырмау буенча чараларны күрү, күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр, әгәр мондый чара законда каралган булса, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар уздыру буенча тәкъдимнәр бирү турындагы мәсьәләне карарга.

41. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру барышында урман законнарының мәҗбүри таләпләрен бозу ачыкланган очракта, мондый бозуны ачыклаган вазифаи зат тикшерү акты төзелгән көннән алып өч эш көне эчендә күрсәтелгән актның күчермәсен чаралар күрү өчен дәүләт күзәтчелеге вәкаләтле органына җибәрергә тиеш.

42. Тикшерү чарасын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә. Тиешле зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирергә, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

43. Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чара уздыру тәмамлангач, контроль чара акты төзелә. Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә. Ачыкланган хокук бозу бетерелгән очракта, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чараны уздыру тәмамланганчыга кадәр, актта аны бетерү факты күрсәтелә. Актка мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләре булган документлар, башка материаллар беркетелергә тиеш. Контроль чара уздырганда тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү контроль чара үткәрелгән урында мондый чараны уздыру тәмамланган көнне башкарыла.

Прокуратура органнары белән килештерелгән контроль чара акты контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры аша аны рәсмиләштергәннән соң турыдан-туры прокуратура органнарына җибәрелә.

44. Контрольдә тотылучы затларга вазифаи затлар кылган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында мәгълүмат бирү әлеге гамәлләр һәм контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында карарлар турында белешмәләрне урнаштыру, шулай ук аларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура ярдәмендә контрольдә тотучы затларга җиткерү юлы белән гамәлгә ашырыла, шул исәптән "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (алга таба - дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы).

Контрольдә тотылучы зат булган эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган граждан аның тарафыннан кәгазьдә документлар җибәрү юлы белән кылына торган вазифаи зат һәм кабул ителә торган карарлар турында аларга вәкаләтле органга кәгазьдә документлар алу кирәклеге турында хәбәрнамә юлланган очракта яки вәкаләтле органның контрольдә тотылучы затның электрон почтасы адресы турында белешмәләр булмаганда һәм аңа документларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша электрон рәвештә җибәрү мөмкинлеге турында хәбәр итә (контрольдә тотыла торган затның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында хисап язмасы булмаса). Күрсәтелгән граждан вәкаләтле органга документларны кәгазь чыганакта җибәрергә хокуклы.

45. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган карарларына, вазифаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда шикаять бирүнең судка кадәрге тәртибе кулланылмый.

46. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда вазифаи затлар билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, хокук саклау органнары, оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итәләр.

47. Муниципаль урман контролен мәгълүмати тәэмин итү максатларында вәкаләтле орган кирәкле белешмәләрне контроль төрләренең бердәм реестрына һәм контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына тапшыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган мәгълүмат системалары төзергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
территориясендә муниципаль
урман контроле турында
Нигезләмәгә 1нче кушымта

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркынычлык категорияләренә кертү критерийләре

1. Контрольдә тотылучы затларның контроль объектын югары куркынычлылык категориясенә кертү критерийлары булган эшчәнлек төрләре:

а) төзелеш;

б) су белән тәэмин итү;

в) файдалы казылмалар чыгару.

2. Контрольдә тотылучы затларның контроль объектын уртача куркынычлылык категориясенә кертү критерийлары булган эшчәнлек төрләре:

а) кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге;

б) эшкәртү производствосы;

в) авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү;

г) туристлык-рекреацион эшчәнлек.

3. Контрольдә тотылучы затларның урта яисә уртача куркынычлылык категориясенә кертелмәгән башка эшчәнлеге түбән куркынычлылык категориясенә керә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
территориясендә муниципаль
урман контроле турында
Нигезләмәгә 2нче кушымта

## Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары:

1) автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнарны кулланганда, юл буендагы урман мәйданнарын су басу, сазлыклану һәм җир өсте һәм туфрак эчендәге су агышы бозылу;

2) урманнарда янгын һәм санитария куркынычсызлыгы кагыйдәләре үтәлмәү;

3) файдалы казылмаларның барлыгын тикшерү һәм чыгару өчен урманнардан файдалану;

4) агулы химик препаратлардан файдалану;

5) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;

6) сервитут һәм урманнарны үзләштерү проектын рәсмиләштермичә линияле объектлар, шулай ук сусаклагычлар, башка ясалма су объектлары һәм (яисә) гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү чаралары башкару;

7) урман эшкәртү инфраструктурасын урнаштыру;

8) Россия Федерациясенең Кызыл китабына яисә Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән файдалану;

9) урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм урман кишәрлекләре туфрагын зарарлау;

10) урман кишәрлекләрен төзелеш һәм көнкүреш чүп-чары, агач калдыклары, калдыкларның башка төрләре белән чүпләү;

11) урман кишәрлеген үзләштерү проектында каралмаган объектлар төзү яки чаралар башкару;

12) урман кишәрлекләреннән файдалану өчен нигез булып торган документларны рәсмиләштерү буенча урман законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәмәү (сервитут, урманнарны үзләштерү проекты).